| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 декабрь 2024 ел № 292

**2024 елга һәм 2025-2026 елларның планлы чорына**
**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

Пункт 1

1. Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын 2025 елга расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 1 561 722,53 мең сум күләмендә;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1 561 722,53 мең сум күләмендә.

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгы 0 мең сум күләмендә.

2. Балтач муниципаль районы бюджетының 2026 һәм 2027 еллар план чорына төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2026 елга 1 656 180,57 мең сум һәм 2027 елга 1 762 339,51 мең сум күләмендә.

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:

- 2026 елга 1 656 180,57 мең сум күләмендә, шул исәптән 23 638,4 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар;

- 2027 елга 1 762 339,51 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 51 381,0 мең сум.

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгы 2026 елга 0 мең сум һәм 2027 елга 0 мең сум күләмендә.

3. Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә расларга:

- 2025 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

- 2026 һәм 2027 еллар план чорына әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә.

2 пункт

1. Балтач муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның өске чиген 2026 елның 1 гыйнварына 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга.

2. Балтач муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның өске чиген 2027 елның 1 гыйнварына 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга.

3. Балтач муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 2028 елның 1 гыйнварына 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга.

3 пункт

Балтач муниципаль районы бюджетында 2025 елга керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә, 2026 һәм 2027 еллар план чорына, әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 пункт

1. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

- 2025 елга әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә;

- 2026 һәм 2027 еллар план чорына әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә.

2. Балтач муниципаль районы чыгымнарының ведомство структурасын түбәндәгечә расларга:

- 2025 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;

- 2026 һәм 2027 еллар план чорына әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә.

3. 2025 елга гавами норматив бурычларны үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 160,0 мең сум, 2026 елга 160,0 мең сум, 2027 елга 160,0 мең сум күләмендә расларга.

5 пункт

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

- 2025 елга әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүленеп, 39 389,9 мең сум күләмендә

- 2026 елга 38 024,7 мең сум күләмендә, 2027 елга 37 515,0 мең сум күләмендә, әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә бүленеп.

6 пункт

Хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган территорияләрдә җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен расларга:

- 2025 елга 3 659,6 мең сум күләмендә, әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә бүленеп;

- 2026 елга 4 002,6 мең сум күләмендә; 2027 елга 4 146,2 мең сум күләмендә; әлеге карарга 12 нче кушымта нигезендә бүленеп.

7 пункт

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү өчен һәм торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд акчалары хисабына финанс ярдәме алу өчен Балтач муниципаль районы бюджетында 2025 елга төзелгән килешүләр нигезендә 1 128 мең сум күләмендә, 2026 елга 1 128,0 мең сум күләмендә, 2027 елга 1 128,0 мең сум күләмендә җирлек бюджетларыннан күпфатирлы торак йортларга капиталь ремонт чараларын тәэмин итүгә тапшырыла торган бюджетара трансфертлар, әлеге карарга 19, № 20 кушымталар нигезендә исәпкә алырга.

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 07 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән Балтач муниципаль районы бюджетында җирле бюджетлардан тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар, 2025 елга төзелгән килешүләр нигезендә 335,3 мең сум күләмендә, 2026 елга 335,3 мең сум күләмендә, 2027 елга 335,3 мең сум күләмендә, әлеге карарга 13 һәм 14 номерлы кушымталар нигезендә исәпкә алырга.

8 пункт

1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган түбәндәге бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:

- 2025 елда 1 040 687,83 мең сум күләмендә әлеге карарга 15 номерлы кушымта нигезендә;

- 2026 елда 1 098 034,57 мең сум һәм 2027 елда 1 164 855,61 мең сум күләмендә әлеге карарга 16 номерлы кушымта нигезендә.

9 пункт

1. Бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (дәүләт һәм Балтач муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгым төрләре төркемнәре, бюджет

чыгымнарының классификацияләү бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

- 2025-2027 елларга әлеге карарга 17,18 нче кушымталар нигезендә.

10 пункт

1.Балтач муниципаль районы Юллар фондының 2025 елга бюджет ассигнованиеләре күләмен 21 632,4 мең сум, 2026 елга 22 423,3 мең сум, 2027 елга 23 120,7 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2025, 2026 һәм 2027 елларга Балтач муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлтергә.

11 пункт

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хакимияте органнары 2025 елда һәм 2026 һәм 2027 елларның планлы чорында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хакимият органнары, муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмалар хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2025 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмаларның хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

12 Пункт

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Балтач районы буенча Казначылык департаментының территориаль бүлекчәсе төзелгән килешүләр нигезендә Балтач муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

13 пункт

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, мәҗбүри таләпләрне бозган өчен Балтач муниципаль районы бюджетына күчерелгән салым булмаган керемнәр, әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча, мәҗбүри таләпләрне бозган өчен, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны ирекле түләгәндә, мәҗбүри таләпләрне бозган өчен административ штрафлардан әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны ачыклау һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны бетерү эшләрен оештыруга, әйләнә-тирә мохиттә, шул исәптән су объектларында китерелгән зыянны булдырмау һәм (яисә) хуҗалык һәм тискәре йогынтыны киметү буенча башка чараларга, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау,

табигать ресурсларын саклау өлкәсендә вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын саклау буенча вәкаләтле орган тарафыннан расланган чараларны булдыруга һәм бәяләүгә җибәрелә дип билгеләргә.

14 пункт

Балтач муниципаль районы бюджетының 2024 елда муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Балтач муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар буенча түләүгә файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан калган акчалары Балтач район башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул иткән очракта 2025 елда күрсәтелгән максатларга ассигнованиеләр тиешле бюджет акчаларын арттыруга җибәрелә.

15 пункт

Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

16 пункт

Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

17 пункт

Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, икътисад һәм социаль-икътисадый үсешне фаразлау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р.Р.Нотфуллин